МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 176/о

ПРИКАЗ "17" 10 2018 БОЕРЫК

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 29 декабрендәге 235/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 29 декабрендәге 235/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 23 апрелендәге 69/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура

һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык
министрлыгының 2018 елның
«17» 10 № 176/о
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 29 декабрендәге 235/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 29 декабрендәге 235/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 23 апрелендәге 69/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектлары төзелешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.3.6 пунктта «белешмәләрне үз эченә ала» сүзләреннән алда «Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге» сүзләрен өстәргә;

1.5 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).».»;

2.3 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төзелешкә рөхсәткә мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогы озынайтылуга бәйле рәвештә үзгәрешләр кертү (алга таба – төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайту);»;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.5.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Хокук күчүе турында хәбәрләмәгә мөрәҗәгать итүче югарыда аталган документларның күчермәләрен теркәргә хокуклы»;

2.5.4 пунктта:

1 пунктчада «яшел кишәрлеккә» сүзләреннән соң «, шул исәптән сервитут билгеләнүе турында килешү, гавами сервитут билгеләнүе турында карар» сүзләрен өстәргә;

3 пунктчада «һәм территорияне ызанлау проекты реквизитлары» сүзләреннән соң «(линияле объектны төзү, үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру буенча документация таләп ителми торган очраклардан тыш), урнаштырылуы өчен җир кишәрлеген оештыру таләп ителми торган линияле объект төзелешенә рехсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру реквизитлары» сүзләрен өстәргә;

4 пунктчада:

«б» пунктчасында «гамәлдә булу зоналары» сүзләрен төшереп калдырырга;

«ж» пунктчасында «яки демонтажга» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

«12) урнаштырылуына бәйле рәвештә, Россия Федерациясе законнары нигезендә территориясеннән файдалануда махсус шартлары булган зона билгеләнергә тиешле капиталь төзелеш объекты төзелгән яки, нәтиҗәдә үзгәртеп корылачак объектка карата территориядән файдалануда махсус шартлары булган зона билгеләренергә яки элегрәк билгеләнгән территориядән файдалануда махсус шартлары булган зона үзгәртелергә тиешле капиталь төзелеш объектын үзгәртеп корган очракта, территориядән файдалануда махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карар күчермәсе.»;

2.5.5 пунктның дүртенче абзацын көчен югалткан дип танырга;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының беренче абзацында «1, 3 һәм 7 пунктчаларда» сүзләрен «1-7, 10 һәм 12 пунктчаларда» сүзләре белән, «2.5.5 пунктның 1 пунктчасында» сүзләрен «2.5.4 пунктның 1, 4 һәм 5 пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга, «күчемсез мөлкәтнең дәүләт реестрында» сүзләреннән соң «яки бәяләмәләрнең бердәм дәүләт реестрында» сүзләрен өстәргә;

2.9 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

1. Төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту нигезләре:

әлеге Административ регламентның 2.5.4 пунктында каралган документларның булмавы;

линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, тапшырылган документларның территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты (линияле объектны төзү, үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру буенча документация таләп ителми торган очраклардан тыш) таләпләренә, шулай ук җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалану таләпләренә һәм (яки) Россия Федерациясенең җир һәм бүтән законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләргә һәм төзелешкә рөхсәт бирү датасына гамәлдә булган рөхсәтле төзелешнең, үзгәртеп коруның чик дәрәҗә параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

2. Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу чорын озынайтудан баш тарту нигезләре:

1) хокук күчүе турында хәбәрләмәдә күрсәтелгән белешмәләрнең төгәл булмавы;

2) планлаштырылучы капиталь төзелеш объектын урнаштыруның капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата, РФ ШрК 51 статьясының 21.7 өлешендә каралган очракта, җир кишәрлеге оештыруның шәһәр төзү планын бирү датасына билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве. Бу вакытта җир кишәрлегенең шәһәр төзү планы РФ ШрК 51 статьясының 21.10 өлешендә күрсәтелгән хәбәрләмәне җибәргән көннән башлап өч елдан иртәрәк булмаган чорда бирелгән булырга тиеш;

3) Министрлыкта дәүләт төзелеш күзәтчелеге, дәүләт җир күзәтчелеге яки муниципаль җир контроле кысаларында ачыкланган мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайту турында гариза тапшырган көнгә төзү, үзгәртеп кору буенча башланган эшләрнең булмавы факты турында мәгълүматның яки әлеге эшләрне башлау турында хәбәр булмавы турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы мәгълүматының булуы, әгәр мондый хәбәрләмәне җибәрү РФ ШрК 52 статьясының 5 өлешендәге таләпләре нигезендә мәҗбүри булып торса;

4) төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайту турында гаризаны төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамланырга ун эш көненнән азрак вакыт калгач тапшыру.

3. Төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту нигезләре:

1) хокук күчүе турында хәбәрләмәдә РФ ШрК 51 статьясының 21.10 өлешендәге 1-4 пунктларында каралган документларның реквизитлары булмау яисә, РФ ШрК 51 статьясының 21.13 өлешендә күрсәтелгән очракта, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документның булмавы яки әлеге Административ регламентның 2.5.4 пунктында каралган документларның булмавы;

2) хокук күчүе турында хәбәрләмәдә күрсәтелгән белешмәләрнең төгәл булмавы;

3) планлаштырылучы капиталь төзелеш объектын урнаштыруның капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата, РФ ШрК 51 статьясының 21.7 өлешендә каралган очракта, җир кишәрлеге оештыруның шәһәр төзү планын бирү датасына билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве. Бу вакытта җир кишәрлегенең шәһәр төзү планы РФ ШрК 51 статьясының 21.10

өлешендә күрсәтелгән хәбәрләмәне җибәргән көннән башлап өч елдан иртәрәк булмаган чорда бирелгән булырга тиеш;

4) планлаштырылучы капиталь төзелеш объектының җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга һәм (яки) Россия Федерациясенең җир һәм бүтән законнары нигезендә билгеләнгән һәм, РФ ШрК 51 статьясының 21.7 өлешендә каралган очракта, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итү датасына гамәлдә булган чикләмәләргә туры килмәве;

5) планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын урнаштыруның рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик дәрәҗә параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

6) төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гаризаны төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамланырга ун эш көненнән азрак вакыт калгач тапшыру.»;

3.6.1 пунктта беренче абзацны «һәм территорияне ызанлау проекты реквизитлары» сүзләреннән соң «(линияле объектны төзү, үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру буенча документация таләп ителми торган очраклардан тыш),» сүзләрен өстәргә, «Россия Федерациясенең җир һәм бүтән законнары нигезендә билгеләнгән һәм» сүзләреннән соң «төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итү датасына гамәлдә булган» сүзләрен өстәргә;

3.6.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2. Тапшырылган документлар территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты таләпләренә (линияле объектны төзү, үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру буенча документация таләп ителми торган очраклардан тыш), шулай ук җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга һәм (яки) Россия Федерациясенең җир һәм бүтән законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләргә һәм төзелешкә рөхсәт бирү датасына гамәлдә булган рөхсәтле төзелешнең, үзгәртеп коруның чик дәрәҗә параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәгән очракта һәм (яки) төзелешкә рөхсәт бирүдән, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайтудан, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булган очракта, Бүлек белгечләре, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының имзасы белән төзелешкә рөхсәт бирүдән (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озынайтудан, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында хәбәрләмә әзерли һәм мөрәҗәгать итүче (аның вәкаләтле вәкиле) адресына җибәрә.»;

3.6.3 пунктта беренче абзацны «һәм территорияне ызанлау проекты реквизитлары» сүзләреннән соң «(линияле объектны төзү, үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру буенча документация таләп ителми торган очраклардан тыш),» сүзләрен өстәргә, «Россия Федерациясенең җир һәм бүтән законнары нигезендә билгеләнгән һәм» сүзләреннән соң «төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итү датасына гамәлдә булган» сүзләрен өстәргә;

5.2 пунктта:

1 пунктчада «мөрәҗәгать итүчене» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктчада «каралмаган документларны тапшыруны» сүзләрен «тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматны тапшыруны яисә гамәлләрне башкаруны» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны мөрәҗәгать итүчедән таләп иткәндә».»;

5.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

5.8 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.».